КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 10 март г.Казань № 185

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы мәсьәләләре» 2011 ел, 6 июнь, 460 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы мәсьәләләре» 2011 ел, 6 июнь, 460 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 26 март, 189 нчы; 2016 ел, 16 июнь, 407 нче; 2016 ел, 19 август, 572 нче; 2016 ел, 27 октябрь, 789 нчы; 2018 ел, 31 июль, 621 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1142 нче; 2019 ел, 18 март, 188 нче; 2020 ел, 2 март, 158 нче; 2020 ел, 13 май, 382 нче; 2020 ел, 7 август, 665 нче; 2021 ел, 2 март, 114 нче; 2021 ел, 28 июнь, 503 нче; 2021 ел, 9 сентябрь, 852 нче; 2021 ел, 6 декабрь, 1169 нчы; 2021 ел, 7 декабрь, 1179 нчы; 2022 ел, 30 сентябрь, 1053 нче; 2022 ел, 21 декабрь, 1388 нче; 2023 ел, 20 март, 294 нче; 2023 ел, 31 июль, 909 нчы; 2024 ел, 27 июнь, 473 нче; 2024 ел, 27 декабрь, 1223 нче; 2025 ел, 5 июнь, 411 нче; 2025 ел, 19 июнь, 445 нче; 2025 ел, 29 декабрь, 1186 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.1 пунктта:

5.1.15 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1.15. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, ведомство бүләкләрен (мактау билгеләрен, бүләкләүнең башка төрләрен) гамәлгә куярга һәм алар белән билгеләнгән өлкәдә эшчәнлек гамәлгә ашыручы Агентлык хезмәткәрләрен һәм башка затларны бүләкләргә.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.1.16, 5.1.17 пунктчалар өстәргә:

«5.1.16. Агентлыкның аеруча тырыш хезмәткәрләренә мактаулы исемнәр бирү һәм аларны Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә кертергә.

5.1.17. Законнар нигезендә башка хокукларны гамәлгә ашырырга.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин